**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 2-58-00 тел./факс +7(84396) 2-58-42, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

8 февраль 2019 ел | Чирмешән авылы | №62

КАРАР

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында" 2019 елның 31 гыйнварындагы 30 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Җирләү һәм җирләү эше турында" 1996 елның 12 гыйнварындагы 8- ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында “Күмү һәм җирләү эше турында " Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, " Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карары, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты " 2019 елда пособиеләр һәм компенсацияләр турында " **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында" 2019 елның 31 гыйнварындагы 30 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2. Карарны түбәндәге эчтәлекле 2 пунктбелән тулыландырырга: "Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының авыл җирлекләре Башкарма комитетлары белән 2019 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге турында

нигезләмәләрне гамәлгә ашыру вәкаләтләре өлешен тапшыру турында килешүләр төзергә".

3. 2, 3, 4 пунктларны 3, 4, 5 пунктлар дип санарга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

Башкрма комитет җитәкчесе И.Н. Шәйдуллин